| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ УРТА КӨШКӘТ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«22» март 2023 ел** **№ 6**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру турында кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында**

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 24.06.1998 № 89-ФЗ, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 10.01.2002 №7-ФЗ, «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 23.11.2009 № 261-ФЗ Федераль законнарга ярашлы рәвештә, 06.10.2003 № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», Татарстан Республикасының 28.07.2004 ТРЗ№45 «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 № 2314 «Тиешсез җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм аларны урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары ягыннан җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында Кагидә раслау турында»карары нигезендә, Урта Көшкәт башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге территориясендә терегөмешле лампаларны беренче җыю һәм вакытлыча урнаштыру урынын билгеләү турында» 22.12.2021 №19 карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урынын) торак булмаган бинада түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Түнтәр авылы, Совет урамы, 26 йорт.

3. Милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган күпфатирлы йортларда тиешсез җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган, кулланучылар файдаланган терекөмешле лампаларны туплану урыннары яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 № 2314 карары белән расланган кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән терегөмешле лампаларның туплану урыннары, әгәр күпфатирлы йортларда терекөмешле лампаларның туплану урыннарын оештыру мөмкин булмаса, бу йортларда кулланучылар файдаланган терекөмешле лампаларны туплану урыныны да булып тора.

5. Кулланучыларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар тупланган урынның (урыннарның) урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Балтач

муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.

6. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми (baltasi.tatarstan.ru) һәм Урта Көшкәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт җирлеге башлыгы Перфилов Ю.М.